ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.08.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1590**

Бердәм дәүләт имтиханы формасында белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча һәм фән олимпиадаларында катнашу нәтиҗәләре буенча Зеленодольск муниципаль районы укучыларына һәм белем бирү оешмалары укытучыларына грант ярдәме күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Бердәм дәүләт имтиханын тапшырганда чыгарылыш сыйныф укучыларының мотивациясен арттыру һәм бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган чыгарылыш укучыларын бүләкләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Бердәм дәүләт имтиханы формасында белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча һәм фән олимпиадаларында катнашу нәтиҗәләре буенча Зеленодольск муниципаль районы укучыларына һәм белем бирү оешмалары укытучыларына грант ярдәме күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә һәм түбәндәге редакциядәге пунктларны бәян итәргә»:

«п.1.4. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучысына 30 мең сум күләмендә грант карала. Берничә фән буенча бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган укучыга грант бер предмет өчен 30 мең сум күләмендә бирелә, ә киләсе фәннәр өчен һәр фән өчен 50 мең сум күләмендә бер тапкыр акчалата бүләк түләнә».

«п.1.4. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан белем алучыларның Бөтенроссия этабында катнашу нәтиҗәләре буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр рәвешендә җиңүчегә - 30 мең сум, призерга - 20 мең сум карала».

«п.2.3. 100 балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучылары өчен материаллар тапшыру срогы – агымдагы уку елының 10 августы».

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 августындагы «Бердәм дәүләт имтиханы формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары һәм фән олимпиадаларында катнашу нәтиҗәләре буенча Зеленодольск муниципаль районы укучыларына һәм белем бирү оешмалары укытучыларына грант ярдәме күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 1682 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе начальнигы Р.В.Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин